| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА<br>И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ<br>ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.12.2016 г.Казань № 249/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында” 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет турында” 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
2016 елның 29 декабрендәге 249/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) каршындагы киңәшмә орган булып тора, ул республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендәге дәүләт сәясәтен булдырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган башка коммерциясез оешмаларның хокукларын гамәлгә ашырга бәйле мәсьәләләрне карый.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм әгъзаларының исәбе Министрлык боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) таянып башкара.

1.4. Иҗтимагый совет чыгарган карарлар тәкъдим рәвешендә була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда алып бара.

1.6. Иҗтимагый совет эше теләк буенча, ачыклык һәм хезмәттәшлек принципларына корыла һәм Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына нигезләнә.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшен гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынуларына нигезләнеп башкара.

2. Иҗтимагый совет эшчәнлеге максатлары һәм бурычлары

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендәге дәүләт сәясәтен булдырганда һәм гамәлгә ашырганда гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнар хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган башка коммерциясез оешмаларның хокукларын яклау;

Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүгә

иҗтимагый, һөнәри һәм иҗади берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итү, Министрлык эшчәнлегенең һәркем өчен ачык булу принцибын тормышка ашыру;

Министрлык тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатына җәмәгать контролен көчәйтү, Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендә ачыклык, законлылык һәм һөнәри осталык принципларын арттыру.

2.2. Иҗтимагый совет бурычларына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендәге дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсенә караган мәсьәләләргә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына җәмәгать экспертизасы үткәрү, шул исәптән Министрлык тарафыннан языла торган дәүләт программалары проектлары турында фикер алышу;

Министрлык карарларын кабул иткәндә җәмәгать фикерен исәпкә алу механизмнарын камилләштерү;

җәмәгатьчелекнең Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча хәбәрдарлыгын арттыру.

2.3. Иҗтимагый совет максатлары һәм бурычлары, аның эш нәтиҗәләренә карап, шулай ук Россия Федерациясендәге икътисадый, социаль һәм сәяси вәзгыятьне исәпкә алып үзгәртелергә һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет составына Иҗтимагый совет рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм, гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциясез оешмалар тәкъдимнәренә нигезләнеп, Иҗтимагый совет әгъзалары кертелә, Иҗтимагый советныц Персональ составы министр тарафыннан раслана.

3.2. Иҗтимагый совет составы үз теләге белән кергән иң күбе 30 кешедән төзелә.

3.3. Иҗтимагый совет составына гражданнар, шул исәптән иҗтимагый оешмаларның һәм социаль юнәлештәге башка коммерциясез оешмаларның вәкилләре булып торучы гражданнар керә ала. Бу вакытта аларның Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр турында фикер алышу өчен кирәкле һөнәри осталыклары, шул исәптән тиешле белеме, әлеге өлкәдәге эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән беррәттән Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән затлар кертелә, аларның саны Иҗтимагый совет әгъзаларыныц гомуми санынннан яртысы кадәр була.

Иҗтимагый совет составына элек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затлар керергә мөмкин, аларның

саны Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән бер өлешеннән артык була алмый.

3.4. Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, суд карары белән юридик хокукы булмаган дип танылган затлар, үтәлеп бетмәгән яки кире алынмаган суд хөкеме чыгарылган затлар, шулай ук “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында” 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаган затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар.

3.5. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый советның беренче утырышында ачык тавыш бирү юлы белән, алар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысыннан күбрәге тавыш биргән очракта, Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан сайлап куела. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын сайлап кую турында карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын вазыйфадан азат итү турындагы мәсьәлә министр мөрәҗәгать иткәч карала, шулай ук аларның шәхси гаризасы буенча яки Иҗтимагый советның барлык әгъзалары санынан биштән бер өлеше тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала.

Карар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынан яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракта туктатыла:

Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында үзе гариза бирсә;

Сәламәтлеге торышы буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаса, башка сәбәпләр аркасында Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән үз ихтыяры белән читләшсә;

аңа карата суд тарафыннан чыгарылган гаепләү хөкеме законлы көченә керсә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә аның юридик хокукы булмау танылса яки яшәгән урынында булмавының сәбәбе билгесез булса;

аның тарафыннан этик нормалар тупас бозылса – утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының күпчелеге тарафыннан кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә җитди сәбәпләрсез системалы (рәттән өч тапкырдан күбрәк) катнашмаса;

Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының йөкләмәләрен җитди сәбәпләрсез системалы (рәттән ике тапкырдан күбрәк) үтәмәсә;

әлеге Нигезләмәнең 3, 4 пунктларында күрсәтелгән вазыйфага билгеләнсә;

чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алса.

3.7. Иҗтимагый советта әгъза булып торуны туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы йә Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары

тәкъдиме буенча, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында каралган шартлар ачыкланган очракта кабул ителә торган министр карары нигезендә башкарыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы сәламәтлеге торышы аркасында эшчәнлек алып бара алмаган, аңа карата суд тарафыннан чыгарылган гаепләү хөкеме законлы көченә кергән, Россия Федерациясе гражданлыгы беткән очракта Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге фактлар турында Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча кабул ителгән министр карары нигезендә түбәндәге очракларда туктатылып тора:

Россия Федерациясе җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә аңа җинаять кылуда гаепләү белдерелсә;

аңа административ кулга алу рәвешендә административ җәза билгеләнсә;

ул дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы кешесе яки вәкаләтле вәкиле буларак теркәлсә, шулай ук ул Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына керсә.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

Министрлык инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, “түгәрәк өстәл”ләрдә) катнашырга, моңа федераль законнар нигезендә, дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрне, персональ белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат һәм файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүмат кулланылганга күрә, аерым кешеләр генә катнаша алган чаралар керми;

Иҗтимагый советка, инициатива күрсәтеп, аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм юлларга;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышына чакырыла торган затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе биргән йөкләмәләрне үтәргә;

әлеге Нигезләмәдә каралган Иҗтимагый советның эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет тарафыннан төзелә торган эксперт, эшче төркемнәрнең, комиссияләрнең, башка эшче органнарның эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет утырышында Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча раслана торган планнар һәм программаларга нигезләнеп оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзаларының, Иҗтимагый совет рәисенең һәм Министрлыкның тәкъдимнәренә нигезләнеп башкарыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Министрлык инициативасы буенча Министрлык тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнеп, әлеге башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында фикер алышуга чыгарылмыйча кабул ителә алмаган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында” 2013 елның 29 мартындагы 214 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнеп, әлеге башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында фикер алышуга чыгарылмыйча кабул ителә алмаган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган норматив хокукый актларның проектларына бәяләмә бирү максатларында үткәрелә.

5.4. Иҗтимагый совет утырышында Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул хокукый көчкә ия була. Иҗтимагый совет әгъзасы шәхсән үзе утырышта катнаша алмаса, үз тавышын һәм көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы фикерен язма рәвештә, факсимиль яки электрон элемтә почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшырырга хокуклы, бу хакта Иҗтимагый совет рәисенә, яки рәис урынбасарына, яисә Иҗтимагый советның җаваплы секретарена хәбәр итәргә тиеш. Утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзаларына үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да кушыла.

Иҗтимагый совет әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын (норматив хокукый актларны) аларның Министрлык тарафыннан Иҗтимагый советка җибәрелү көненнән башлап ун календарь көн эчендә карап тикшерә. Мондый очракта алар буенча Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында тавыш бирү Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру рәвешендә утырыштан читтә тавыш бирү юлы белән башкарылырга мөмкин. Сораштыру нәтиҗәләре беркетмәгә теркәлә, ул Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаган очракта – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан имзалана. Шул рәвешле тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон элемтә чараларын кулланып яки җибәрелә һәм алына торган хәбәрләрнең аутент булуын һәм аларның документаль раслануын тәэмин итә торган башка элемтә чараларын кулланып документлар алмашу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Тавыш бирү утырыштан читтә үткәрелсә, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына тәкъдим ителә торган көн тәртибе, Иҗтимагый совет тарафыннан бәяләмә бирелергә тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) аны уздыру көненә кадәр кимендә җиде календарь көн алдан җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары Министрлыктан,

кирәк булган очракта, карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат соратып алалар.

Иҗтимагый совет карарлары тавышларның гади күпчелеге булганда кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышын Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаган очракта – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Иҗтимагый советка йөкләнгән максатларга, бурычларга, вәкаләтләргә ярашлы кабул ителә торган карарлар тәкъдим буларак чыгарыла һәм әлеге карарлар кирәк булган затларга Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яисә Иҗтимагый совет сайлаган башка ысул белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Министрлык сайтына “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет” бүлегенә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәренә нигезләнеп Иҗтимагый советның эш планын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына кертә;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет тәкъдимнәрен, беркетмәләрен һәм башка документларын имзалый;

Иҗтимагый совет утырышларын уздыру вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максат һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән соратуларны, тәкъдимнәрне, җавапларны, аңлатмаларны һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләр башкара.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә үз урынында булмаган вакытта аның функцияләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисе раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәкъдим итү өчен кирәкле башка функцияләр башкара.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышын уздыру урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмат-белешмә материаллары белән тәэмин итә;

оештыру эшләрендә Иҗтимагый совет белән Министрлыкның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәргә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне башкара;

Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен күзәтеп бара;

Иҗтимагый совет утырышларының кон тәртибен төзү эшләрендә катнаша.

5.11. Авыл хуҗалыгын үстерү һәм Иҗтимагый совет компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү максатларында Иҗтимагый совет комиссияләр төзергә хокуклы, аларның составына Министрлык белән килештерелгән дәүләт граждан хезмәткәрләре, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар вәкилләре кертелергә мөмкин.

Иҗтимагый совет әгъзалары мәсьәләләрне Иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга әзерләү өчен эксперт, эшче төркемнәргә һәм башка эшче органнарга берләшергә, материаллар әзерләү эшенә, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештереп, Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне җәлеп итәргә хокуклы.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет карый торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен башкарма органнар, коммерциясез оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар җәлеп ителергә мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында була ала.

5.13. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар алар каралырга тиешле Иҗтимагый совет утырышы билгеләнгән датага кадәр кимендә ун көн кала Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны соң срокларда тапшыру Иҗтимагый совет рәисе белән яки рәис урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген техник яктан һәм оештыру ягыннан тәэмин итү Министрлык тарафыннан башкарыла.